**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы**
**Макаровка авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

№21 2015 елның 15 июне

## Өченче чакырылыш Макаровка авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукы төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3,7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13 статьясы нигезендә, Макаровка авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Өченче чакырылыш Макаровка авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны 2015 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Нижнекамская правда», «Туган Як» газеталарында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында http://www.e-nkama.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Макаровка авыл җирлеге
башлыгы Т. К. Ладнушкина